

Унынчы январьда Мордовия Республикабыз тарихында моһим датаны - Мордовия автономиясе оешуга 95 ел тулуны билгеләп vттек.

Әлеге юбилей - кvпьеллык хезмәт, уникаль тобәгебезнен vсеше һәм казанышлары символы – Автономия формалашунын озын һәм бай юлын узган. Бу истәлекле конне торле мәйданчыкларда торле чаралар vтте. Мәсәлән, «Бердәм Россия» партиясе тарафдарлары штабында «Моһим нәрсәләр турында сойләшv» узды. Аны Мордовия автономиясенен 95 еллыгына багышладылар. Анда Средне-Волжский институт ВГУЮ (РПА Минюста РФ) студентлары тарихчы Иван Капитонов белән аралашты.   Унысы конне 1941-1945 еллардагы хәрби һәм хезмәт батырлыгы мемориаль музеенда олы датага багышланган кvргәзмә ачылды. «Вакыйгаларда һәм затларда Мордовия автономиясенен 95 еллыгы» кvргәзмәсендә фото-сурәтләр һәм архив документлары тәкъдим ителгән иде. Биредә Рус драма театры тозелешенен башлануын, Мемориаль музейнын беренче нигезе салынуын, республикабызнын кvренекле кешеләрен кvрергә момкин. Сурәтләрдә шулай ук милли тобәктә яшәvчеләрне берләштерә торган моһим вакыйгалар һәм бәйрәмнәр кvрсәтелгән.



Искәртеп китәбез, 2025 ел дәвамында Республикада Мордовия автономиясенен 95 еллыгына бәйле кvпсанлы чаралар узачак. Саранскида һәм республика районнарында бу вакыйгага кvпсанлы кvргәзмәләр, концертлар, белем бирv программалары багышланачак. Ә январь ахырында Мордовия башкаласында ботен Россиядән килгән кунаклар катнашында зур тантаналы жыелыш узачак.